**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

31.10.2022 № 353

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасына кандидатураларны карау һәм раслау тәртибе турында» боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасына кандидатураларны карау һәм раслау тәртибе турында» 2005 елның 8 ноябрендәге 320 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 19 ноябрендәге 305 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге 97 номерлы, 2011 елның 13 апрелендәге 171 номерлы, 2012 елның 7 декабрендәге 550 номерлы, 2014 елның 5 маендагы 310 номерлы, 2015 елның 2 ноябрендәге 640 номерлы, 2017 елның 18 сентябрендәге 557 номерлы һәм 2019 елның 16 ноябрендәге 376 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасына кандидатураларны карау һәм раслау тәртибе турында нигезләмәнең 2 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасына кандидатларны алдан карау буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы комиссия (алга таба – Комиссия) составында:

Комиссия составыннан А.А. Нефедовны, Т.Җ. Сөләймановны, А.М. Терентьевны чыгарырга;

Комиссия составына кертергә:

Әхмәтвәлиев Тимур Дамир улын – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы урынбасарын;

Кондратьева Алла Андреевнаны – Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры урынбасарын;

Комиссия рәисе урынбасары итеп раслап, Мөхәрләмов Руслан Робе́рт улын – Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесен;

Комиссия рәисе Ә.Ә. Сәфәровның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе Җитәкчесе, Комиссия рәисе».

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**